ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
« 24 » декабрь 2020 ел.

**КАРАР**
№ 14

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 21 июнендәге 14 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион уздыру тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Акционерлык җәмгыятьләре турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 8 февралендәге N 14-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Шубан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибе турында" 2017 елның 21 июнендәге 14 номерлы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган ,"Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибе турында" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 пунктның «в» пунктчасында «мөрәҗәгать итүченең таныкланган мөһере» сүзләреннән соң «(мөһер булу турындагы белешмәләр җәмгыять уставында булса)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Шубан авыл җирлеге башлыгы: Мөҗипов Р.Р.